ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЙБИЦКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

22.01.2025 Олы Кайбыч ав. № 14

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздыру турында

Җир кишәрлекләре хокук ияләренең уңай яшәү шартларына, тормыш эшчәнлеге, хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатларында, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР ИТӘ:

1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздыруны билгеләргә.

2. 2025 елның 21 февралендә 10.00 сәгатьтә Кайбыч районы, Олы Кайбыч авылы, Кояшлы бульвар авылы, 7 йорт адресы буенча урнашкан Иҗтимагый үзәк бинасының актлар залында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Генераль планы проекты буенча гавами тыңлаулар уздырырга.

3. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Генераль планы проектында булган материаллар (текст һәм график өлеш) белән эш көннәрендә 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр түбәндәге адрес буенча танышырга була: Татарстан Республикасы, Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 йорт, 2нче кат, 209 нчы кабинет.

3.1. Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Генераль планы проекты буенча тәкъдимнәр һәм кисәтүләр җыю урыны итеп Кайбыч районы, Олы Кайбыч ав., Кояшлы бульвар, 7 й., 2 кат, 209 нчы кабинет адресы буенча урнашкан Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлеген билгеләргә.

4. Кайбыч муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктура үсеше бүлегенә:

-«Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы «Колаңгы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең гавами тыңлаулар билгеләү турында мәгълүмат урнаштырырга;

әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең төзелеш һәм ТКХ буенча урынбасары Е.Г. Давыдовага йөкләргә.

Җитәкче А.Н. Макаров